СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел Алабуга шәһәре № 46

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Җирле үзидарә органнарының сайланулы вазифасын, муниципаль хезмәт вазифасын, әгәр граждан муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән алып ике ел дәвамында хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазифа биләсә һәм (яисә) әлеге оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарса, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарәнең аерым функцияләре аның вазифаи (хезмәт) бурычларына керсә, Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенең муниципаль вазифасын биләгән граждан тарафыннан хәбәр итү һәм үтәлешен тикшерү тәртибе турында» 2013 елның 7 февралендәге 293 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуроры протестын караганнан соң, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 7 февралендәге 293 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнарының сайланулы вазифасын, муниципаль хезмәт вазифасын, әгәр граждан муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән алып ике ел дәвамында хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазифа биләсә һәм (яисә) әлеге оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарса, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарәнең аерым функцияләре аның вазифаи (хезмәт) бурычларына керсә, Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенең муниципаль вазифасын биләгән граждан тарафыннан хәбәр итү һәм үтәлешен тикшерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертеогә:

1.1. Тәртипнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Комиссия, әгәр әлеге оешманың муниципаль (административ) идарәсенең аерым функцияләре аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазифа биләүгә һәм (яисә) шул оешмада эшләр башкаруга (әлеге оешмага хезмәтләр күрсәтүгә) ризалык бирү турында гражданның язма мөрәҗәгатен карарга, шулай ук кабул ителгән карар турында гражданга хәбәр итәргә тиеш.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов